# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт авылы торак пунктында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**2020 елның 13 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 13 ноябрендә 13.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 350 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлеге территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнардан (студентлар, Кораллы Көчләр сафларында хезмәт итүче затлар), I һәм II төркем инвалидлардан һәм 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнарданнар, хөкем ителгәннәр), тормышта авыр хәлдә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

-Яңа Әхмәт авылында вак таштан юлларны төзекләндерү;
- Яңа Әхмәт авылы зиратында йорт төзү өчен материаллар сатып алу;
-Яңа Әхмәт авылы мәдәният йорты өчен музыкаль җиһаз сатып алу;
-Яңа Әхмәт авылында балалар спорт мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 177 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 153 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 136 катнашучы тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 17 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.
2. «2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт авылы территориясендә җирлек территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнардан (студентлар, Кораллы Көчләр сафларында хезмәт итүче затлар), I һәм II төркем инвалидлардан һәм 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнарданнар, хөкем ителгәннәр), тормышта авыр хәлдә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

-Яңа Әхмәт авылында вак таштан юлларны төзекләндерү;
- Яңа Әхмәт авылы зиратында йорт төзү өчен материаллар сатып алу;
-Яңа Әхмәт авылы мәдәният йорты өчен музыкаль җиһаз сатып алу;
-Яңа Әхмәт авылында балалар спорт мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Сарман авыл җирлегенең Сарман мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман авылы башкарма комитеты
җитәкчесе
гражданнар җыенында рәислек итүче Н.И.Сахуриев